КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 10 гыйнвар г.Казань № 5

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе турында» 2022 ел, 15 июнь, 557 нче карары белән расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирү конкурсларын үткәрү буенча республика комиссиясе турында» 2022 ел, 15 июнь, 557 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 30 гыйнвар, 78 нче; 2023 ел, 22 март, 324 нче; 2023 ел, 13 июль, 828 нче; 2023 ел, 28 декабрь, 1709 нчы; 2024 ел, 22 май, 355 нче; 2024 ел, 13 август, 651 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирү конкурсларын үткәрү буенча республика комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Игорь Измаилович Бикеевның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«В.Г.Тимирясев исемендәге Казан инновация университеты» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесенең беренче проректоры, фәнни эшләр буенча проректоры (килешү буенча)»;

Тимур Ренат улы Камалетдиновның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ФОРПОСТ» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләре республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты»;

Мария Викторовна Крюкованың вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең «УРАМ» яшьләр экстрим-паркы директоры, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы»;

Елена Ивановна Кузьмичеваның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе» берлеге рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча)»;

Ринат Рафаэль улы Фазыловның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия өчен» халык фронты» гомумроссия иҗтимагый хәрәкәтенең «Татарстан Республикасындагы төбәк башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча)»;

Данис Фәнис улы Шакировның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бөтендөнья татар конгрессы Милли советы рәисенең беренче урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин